# Безнен МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

06

июнь 2022

ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

## Мордовиядә татар утравы: ләмберә һәм түбән татарлары, эрзәләр

*4 бит*

## Колынчаковлар утарында

*80 бит*



# Өзелгән җыр



**Шәүкәт Галиев (сулда) һәм Самат Шакир мәктәп музеенда**

Казанда Яңа Савин районының Балалар һәм яшүсмерләр туризмы һәм экскурсияләр йортында Балалар әдәбияты музее бар. Бу музей үзенчәлекле экспонатларга бик бай. Биредә шагыйрь Шамил Гәрәйнең фотолары, документлары, рәсем альбомы, китаплары, газета төпләмәсе һәм шәхси әйберләре дә урын алган.

Бөек Ватан сугышының дәһшәтле еллары ераклаша бара. Быел халкыбыз фашист илбасарларын җиңүнең 77 еллыгын билгеләп үтте.

Илебез халкы 1941 елда явызларча басып кергән фашист илбасарларына каршы изге көрәшкә күтәрелә. Бу көрәштән әдәбият һәм сәнгать әһелләре – әдипләр, рәссамнар, композиторлар һәм артистлар да читтә калмый. Аларның коралы – повесть һәм драма әсәрләре, хикәяләр, публицистика, очерк, рәсемнәр, җырлар – бер яктан, сугышчыларда патриотик хисләр, Җиңүгә өмет уятса, икенче яктан, дошманга нәфрәт тәрбияли. Шулай итеп, алар үз Ватаннарының азатлыгы өчен мылтык белән генә түгел, ә каләмнәре белән дә көрәшә.

Сугышның беренче көннәрендә 53 әгъзадан торган Татарстан язучылар берлегеннән 25 кеше фронтка китә: М.Җәлил, Ф.Кәрим, С.Хәким, Ә.Исхак, Г.Кутуй, Ә.Фәйзи, Т.Хуҗиев, С.Баттал, Н.Дәүли, Г.Әпсәләмов һ.б.

Сугыштан кайтмый калган язучылар арасында минем әниемнең абыйсы Шамил Гәрәй дә бар.



туризмы һәм
зенчәлекле экс-
документлары,
е дә урын алган.
і халкыбыз фа-

сарларына кар-
ләре – әдипләр,
рның коралы –
емнәр, җырлар
, икенче яктан,
азатлыгы өчен

стан язучылар
Э.Исхак, Г.Кутуй,

ең абыйсы Ша-





Ә кем соң ул Шамил Гәрәй?






Шамил Гәрәй – Казан тумасы. Ул бирейдә 1916 елның 31 декабрендә хезмәткәр гаиләсендә дөньяга килә.

Дәү әнинең сөйләве буенча, аларның гаиләсе башта Татарстан (Евангелистская) урамындагы 66 нчы йортта яшәгән. Аннары К.Маркс урамындагы 8 нче йортка күченгәннәр.

Әтисе Мөхәммәтгали – Вахитов исемендәге сабын заводында, ә әнисе Рабига тегү фабрикасында эшләгән. Гаиләдә, Шамилдән кала, ике кыз бала булган: Рәйсә һәм Ләлә. Ләлә театр техникумын тәмамлый, соңыннан ул завод эшчесе була. Рәйсә исә хезмәт юлын хисапчы һөнәре белән бәйли.

Шамил Гәрәй Тукай урамында урнашкан Гаспринский мәктәбендә укый. Бу мәктәп үз чоры өчен көчле мәктәпләрдән санала. Шамил анда укыган чагында ук яшьтәшләреннән тырыш һәм сәләтле булуы белән аерылып тора. Ул күп укый, музыка белән кызыксына, гармунда һәм пианинода уйный, рәсемнәр ясый.

Шамилнең архивында рәсем альбомнары саклanган. Аның иң зур кызыксынуы, әлбәттә, – шигърият. Ул үзенең беренче шигырен 10 яшендә иҗат итә.

Фронтовик-рәссам Мансур Рәхимов үзенең балачак хатирәләрендә болай дип искә ала: *Әкияттәге кебек өч дус үстек без. Аның берсе – балалар язучысы, фронтовик шагыйрь – Шамил Гәрәй. Икенчесе – Балтыйк диңгезендә хезмәт иткән фронтовик Әнвәр Сабирҗанов. Уку еллары, егетлек чоры мәңге хәтердә... Һәрберебез тормышта үз юлын, үз кыйбласын табарга тырышты.*

*Шамил Гәрәй шигырьләр язарга ярата иде. Мәктәп елларында ук аның шигырьләре «Яшь ленинчы» газетасында (хәзерге «Сабантуй» журналы. – Ф.С.) даими басылып килде. Эшкә дә шушы газета редакциясенә урнашты...»*

Шамил Гәрәй күп укый, шәһәр китапханәсендә еш була. Аңа бигрәк тә Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Һ.Такташ әсәрләре ошый. Бу язучыларның иҗатын өйрәнү Шамилнең шагыйрь булып формалашуына зур йогынты ясый.

1932 елны аның әтисе вафат була. Шамил җиденче сыйныфны тәмамлый. Аларның гаиләсе бик авыр тормышта яши, аның хәтта язу өстәле дә булмый. Кыз туганнары әйткәнчә, Шамил төннәрен аш өстәле астына кереп, шигырьләрен керосин лампасы яктысында иҗат итә...

Язучы, журналист Ләбиб Лерон «Яшь ленинчы» газетасында (1985) язганча: *«Шамил Гәрәй исеме матбугат битләрендә 30 нчы елларда күренә башлый. 15 яше тулгач, ягъни 1931 елда ул, шигырьләрен күтәреп, «Яшь ленинчы» газетасы редакциясенә килә. «Шигырьләрең миңа ошады», – ди кара тутлы, чәчен бер якка шома итеп тараган иптәш. Бу балалар язучысы Абдулла Алиш була. «Октябрятлар җыры» дигән беренче шигыре газета битләрендә басылып та чыга. Мәшһүр әдип фатихасы белән, Шамил Гәрәй шушы газетаның балалар хәбәрчесе булып китә. Әнә шул көннәрдә аның әдәбиятка юлы ачыла... Бер ел узуга, яшь шагыйрьнең «Сигналчы җыры» исемле беренче китабы дөнья күрә. Бернича елдан «Яшь ленинчы»*

*газетасының әдәби бүлеген җитәкли. «Пионер каләме», «Техника» журналлары һәм башка вакытлы матбугат битләрендә дә шигырьләре, хикәяләре, хәбәр язмалары даими рәвештә басыла башлый...»*

«Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналы редакциясендә эшләгән журналист Мәрьям Дибаева «Элита Татарстана» журналында шагыйрьне болай дип искә алган: *«Шамил Гәрәй дигәч, минем күз алдыма урта буйлы, базык гәүдәле, түгәрәк йөзле егет килеп баса. Күпмедер вакыт ул «Яшь ленинчы» газетасы, «Пионер каләме» журналы редакцияләрендә эшләп алды. Аннары китап нәшриятындамы, башка газета-журналлар редакцияләрендәме, анысын анык белмим, эшләп йөрде. Әмма безнең редакциягә Шамил бик еш килә иде. Яңа язган шигырьләрен укып, бастырып чыгарырга калдыра, хәбәрчеләребездән килгән шигырьләргә күз йөртеп ала, кайчагында аларга үзенең киңәшләрен әйтеп хатлар да яза. Мин аны Абдулла Алиш янында еш очрата идем. Бик күп еллар – ярты гасырдан артык вакыт үткән бит инде. Күп нәрсәләр онытылган. Шулай да Шамил минем хәтеремдә ничектер бик аз сүзле, артык дәрәҗәдә тыйнак бер шәхес булып калган. Әгәр ул, әсирлек һәм тоткынлык газапларын күрмичә, сугыштан исән-имин кайтса, Сибгат Хәкимнәр дәрәҗәсендәге күренекле шагыйрь булыр иде. Без аны бик яшьләй югалттык шул...»*



**Шамил Гәрәйнең китаплары**

Шамил Гәрәйнең һәр шигырен, һәр хикәясен, һәр мәкаләсен балалар көтеп ала. Чөнки шагыйрь алар белән үз күреп, дус итеп сөйләшә. Ул чын иҗат ялкыны белән яна. Абдулла Алиш кебек асыл осталар янында каләме чарланганнан-чарлана бара. Шагыйрь шигъри осталык биеклекләрен яулый. Бер-бер артлы яңа җырлары, яңа китаплары дөнья күрә.

Язучы, галим Җәвад Тәрҗеманов үзенең «Очрашулар, сәяхәтнамәләр, истәлекләр, эзләнүләр һәм әдәби портретлар» дигән китабында мондый юлларны яза: *«1934 нче елда мин, ниһаять, «Пионер каләме» журналына һәм «Яшь ленинчы» газетасына язылдым һәм, үзем дә сизмәстән, әдәби иҗат мәктәбенә килеп кердем. Газета битләрендә Муса Җәлилнең бер-бер артлы басыла барган җырлары, Фатих Кәримнең «Аучы» поэмасы, Г.Мөхәммәтшин һәм Ш.Гәрәй шигырьләре минем өчен шатлыклы яңалык булды.*

*1935 елның сентябрь азакларында Казан Үзәк балалар китапханәсендә «Яшь каләмнәр» берләшмәсе оештырылды. Берләшмәнең җитәкчесе итеп Татарстан Язучылар берлегеннән шагыйрь Галимҗан Мөхәммәтшин билгеләнде. Безнең утырышларга ул бервакытта да үзе генә килми, язучылардан кемне дә булса алып килә. Анда безгә Сафа Гыйльфан, Сибгат Хәким, Шамил Гәрәй, Абдулла Алиш, Фатих Хөсни, Идрис Туктаров үзләренең әдәбияттагы беренче адымнары турында сөйлиләр, яңа әсәрләрен укыйлар иде.*

*Казан Үзәк балалар китапханәсе каршында оештырылган «Яшь каләмнәр» берләшмәсе түгәрәгенең эш дәфтәреннән:*







*«1935 ел, 24 ноябрь*

*Тугызынчы утырыш.*

*Бүген түгәрәккә Шамил абый һәм Сибгат абый Хәким килде.*
*Көн тәртибе:*
*1. Шамил абый Гәрәй белән танышу.*
*2. Төрлеләр.*

*Шамил абый Гәрәй үзенең яшь чагында ничек яза башлавын һәм язган әйберләрен редакциягә ничек илтүен сөйли. Язучы һәм шагыйрь булу өчен үзең алган өлкәне сөя белергә кирәклеген әйтә. Үз китапханәсе булуын һәм рус классикларын күп укуы турында сөйли. Аннан лирик шигырьләргә күчеп, аларның нинди мәгънә белдерүен аңлата. Галиуллин: «Кече яшьтә нинди әсәрләр укыдыгыз? – дип сорый. Ш.Гәрәй: «Кечкенә чагымда Такташ шигырьләрен күп укыдым. Башка жанрларга караганда поэзияне яратам», – ди һәм үзенең шигырьләрен укый...»*

1933 елда Шамил Гәрәйнең – «Флюра», 1934 елда – «Звено җыры», 1937 елда – «Тормыш иртәсе», 1941 елда «Тормыш чәчәкләре» дигән китаплары басылып чыга. Язучы Самат Шакир: *«Шамил Гәрәй шигырь техникасын Г.Тукайдан өйрәнә. Аның шигырьләре сәнгатьчә оста эшләнеше, рифмаларының яңа булуы, ритмнарының төзеклеге белән аерылып тора»,* – дип яза.

Ш.Гәрәйнең әсәрләре күренекле язучылар тарафыннан да хуплана. Шагыйрьнең архивында аларның автографлары язылган китаплар да күп. Ул язучылар белән бергә Урал якларына һәм Харьковка бара. Татарстан Республикасының Үзәк дәүләт архивында бу турыда материаллар саклана.

Ш.Гәрәй үзен тәрҗемә эшендә дә сынап карый. Ул А.Барто шигырьләрен, Л.Квитко, М.Лермонтов, А.Чехов әсәрләрен тәрҗемә итә.

Язучының архивында А.Алиш китаплары да бар. А.Алишның «Минем абыем» китабына автор кулы белән мондый сүзләр язылган: *«Шамил дустыма! Истәлек өчен. А.Алиш. 20.12.40.».*

А.Алишның туганы Илсөяр Сөнкишева истәлегеннән (20.12.1969): *«Язучы Абдулла Алишның Шамил Гәрәй исемле бер яшь дусты булганын беләбез. Яшь аермалары 9 ел чамасы. Шулай булса да, аларны якын дуслар, хезмәттәшләр дияргә мөмкиндер. Бу иҗади дуслык берничә ел дәвам иткән.*

*1933-1936 нчы елларда, Абдулла Алиш татар телендә чыгып килгән «Техника» журналында җаваплы секретарь булып эшләгәндә, яшь иҗат көчләрен, хәтта балаларны-үсмерләрне дә техник темаларга язмалар белән катнаштыра килгән. Менә шушы журналда Шамил Гәрәй дигән авторның да мәкаләләре еш басылган. Шуларның кайберләре:*

*1. «Серле җәдвәл» – «Техника», №8, 1933 ел;*
*2. «Яшь техниклар күргәзмәсендә» – «Техника», №9, 1933 ел;*
*3. «Колхозлардагы техник ударниклар» – «Техника», №10, 1933 ел һ.б.*

*Белгәнебезчә, бу журналның соңгы битләрендә «Балалар бүлеге», «Яшь техниклар почмагы» оештырылып, балалар өчен материаллар бирелеп килгән. Хәзер зур галим, техник фәннәр докторы, Халыклар дуслыгы университеты профессоры Габделхак Галиуллинның да (ул чакта 13 нче мәктәпнең 6 нчы сыйныф укучысы) беренче мәкаләсе шушы журнал битләрендә басылган. Бу мәкалә «Мин ничек телескоп ясадым?» дип атала («Техника», №1, 1934 ел).*

*«Пионерлар һәм мәктәп балалары! Техниканы үзләштерү өчен көрәшкә!», «Яшь техниклар һәм уйлап табучылар күбрәк җитешсеннәр!» дигән лозунг (чакырулар) куелып, шуны тормышка ашыруда журнал үзеннән зур өлеш керткән.*

*Ул елларда Казанда ВОИЗ һәм БРИЗ дигән оешмалар булган (Всероссийское общество изобретателей, Бюро рационализаторов и изобретателей). Ш.Гәрәй мәкаләләренең ахырына еш кына «ВОИЗ комитетыннан» дигән сүзләр язылган. А.Алиш үзе дә БРИЗ члены булган.*

*Аларның бу өлкәдәге эшчәнлекләрен дә өйрәнеп, тиешле бәя бирәсе иде.*

*1933 елның 5-6 июль көннәрендә Шамил Гәрәй слетта катнашкан.*

*Ә 1936 елда Абдулла Алиш белән Харьковка иҗат командировкасына баралар. СССРда беренче булып ачылган Пионерлар сараеның эш тәҗрибәсен өйрәнәләр. Кайткач, берләшмәдә отчет бирәләр. Бу отчет беркетмәләре архивта саклана».*

Шамил А.Алишның улларына багышланган «Алмаз белән Айваз» дигән шигырен язган. Бер әдәби кичәдә укучылар ул шигырьне Алмаз Абдулла улына сөйләде.

Ш.Гәрәйнең берничә шигыре язучы Самат Шакирның «Алар сафта» дигән китабына да кертелгән. Ул китап фронтовик язучылар – М.Җәлил, А.Алиш, Ф.Кәрим, Нур Баян, Ш.Хәйри, Ш.Гәрәйгә багышланган.

Самат Шакир истәлегеннән бер өзек: *«Минем шагыйрь булып китүемә Шамил Гәрәйнең шигырьләре зур тәэсир ясады. Без мәктәптә укып йөргәндә Шамил Гәрәйнең «Урман буенда» җырын күмәкләп җырлый торган идек. Отрядта бу җырны бик зурлап җырлап йөргәнебезне хәтерлим:*

*Җәйге урман.*
*Нарат агачлары*
*Гаскәр кебек тезелеп китkәннәр.*
*Җиләк урыны –*
*Яшел куаклыклар*
*Урман буен бизәп киткәннәр.*
*Салмак кына*
*Йомшак искән җилләр*
*Яфракларны селкеп шаулата,*
*Җырчы кошлар*
*Агач арасыннан*
*Сузып җырлап урман яңгырата.*

*Бу җырның көен композитор Җәүдәт Фәйзи язган.*

*Шагыйрь балаларга туган илебез табигатенең матурлыгы турында сөйли. Аның бу елларда язылган әсәрләрен бәхетле балачак шигырьләре дип атарга мөмкин.*

*Еллар үтте. Мин, Шамил Гәрәйнең шигырьләрен җыеп, «Алар сафта» дигән китап чыгардым. Бу китапка аның биш шигыре керде. Шул шигырьләрне җыеп йөргәндә, Шамил Гәрәйнең әнисе Рабига апа өендә булдым. Ул, елый-елый, улының һәлак булуы турында сөйләде. Мин шуннан соң, Ш.Гәрәйнең барлык шигырьләрен җыеп, «Совет әдәбияты» журналында да бастырып чыгардым...»*

Әнә шундый талантлы каләм иясенең иҗаты чәчәк аткан вакытта илебезгә немец-фашист илбасарлары бәреп керә. Сугышның беренче көннәреннән үк шагыйрь фронтка китә. Аны А.Алиш һәм туганнары озатып кала. Шамил Гәрәй

алгы сызыкта дошманны мылтык һәм каләм белән «кыйный». Каты сугышлардан соң, ял вакытларында ул шигырьләр яза. Мәскәү янындагы сугышларда «Дошман җиңелер!» дигән шигырен язып, «Фронт» газетасында бастыра.

Кече командир Шамил Гәрәй ифрат кыен хәлләргә, күп михнәтләргә тарый. Мәскәү янындагы рәхимсез сугышларның берсендә чолганышта кала, контузия ала, фашистлар кулына әсирлеккә төшә. Ул тимер чыбык киртә эчендә дә үзенең башлаган җырын дәвам итә, фашистларга каршы сатирик шигырьләр яза. Ш.Гәрәйнең туган илен сагынып язган шигырьләре дә булган, ләкин алар югалганнар. Биш елга сузылган тоткынлык чоры эзсез узмый – аның сәламәтлеген какшата. Әсирлектән котылгач, ул Польшаның Гливице шәһәрендәге госпитальдә дәвалана.




Мәкалә авторы Фәридә Сәлимова туганы – шагыйрь Шамил Гәрәйнең кабере янында

Шагыйрьнең туганнары бөтен сугыш дәвамында Шамилдән хат-хәбәр көтә. Фәкать Җиңү көннәреннән соң гына аннан хәбәр килә. Бу аның 1946 елның мартында Польшадан язган соңгы хаты була: *«Кадерле әни, туганнарым Рәйсә һәм Ләлә! Мин, әле сугыш беткәндә, үземне исән-сау кеше итеп сизә идем. Ләкин сугыш елларында күрергә туры килгән газаплар, җәфалар, кичерешләр, нәләт төшкән фашизм Германиясендәге коточкыч авыр шартлар минем организмга да үзләренең төзәлмәслек печатьләрен салганнар. Авыруымның шулай каты икәнен белгән булсам, беренче хатымны сезгә язмаган булыр идем. Нәләт төшкән Германия җирендә торасы килми, туган илгә кайтасы килә...»*

Шагыйрь Шамил Гәрәй 1946 елның 22 мартында дөнья куя.

Аның җәсәден хәрбиләр зиратына җирлиләр.

2012 елда миңа Польшага бару һәм Гливице шәһәрендәге госпитальне күрү насыйп булды, зиратта да булдым.

Шагыйрь Шамил Гәрәй тормышның шиңмәс чәчәкләре булган балаларга дан җырлады. Безнең хәтер булып яши ул җырлар!

***Фәридә Сәлимова,***
*Яңа Савин районының Балалар һәм яшүсмерләр туризмы һәм экскурсияләр йорты каршындагы Балалар әдәбияты музее җитәкчесе* ■